**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ ТАТАРСКО-САРАЛОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
422633,РТ, Лаишевский район, село
Татарские Саралы, ул.Татарстан, д.17
тел: 8-(84378) -4-77-49
факс: 8-(84378) -4-77-49

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАТАР САРАЛАНЫ АВЫЛ**
**ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422633, РТ, Лаеш районы, Татар Сараланы
авылы, Татарстан урамы, 17 нче йорт
тел: 8-(84378) -4-77-49
факс: 8-(84378) -4-77-49

2023елның «26» апреле 126 номер

# КАРАР

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы авыл җирлеге советының «Җир салымы турында» 2021 елның 20 октябрендәге 70 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү максатыннан, Лаеш муниципаль районының Татар Сараланы авыл җирлеге советы карар кылды:

1) Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы авыл җирлеге советының «Җир салымы турында» 2021 елның 20 октябрендәге 70 номерлы карарына, кушымта нигезендә, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2) Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3) Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы
авыл җирлеге Советы рәисе Садыйков А.Б.

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының
Татар Сараланы авыл җирлеге Советының 2023 елның «26» апрелендәге
126 номерлы карарына кушымта

«Җир салымы турында» 2021 елның 20 октябрендәге 70 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Сараланы авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү.»

1) **1) 2.2 пунктындагы «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) тарафыннан вәкаләтләнгән махсуслаштырылган оешмалар милкендәге җир кишәрлекләренә карата 0,001%;".